| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2022 елның «19» сентябре | № 20 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, пеналар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 10 июлендәге 11номерлы карарына (2017 елның 6 июлендәге 15 номерлы редакциядә) үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәр прокуратурасының 2022 елның 16 августындагы 02-08-03 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, пеналар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 10 июлендәге 11 номерлы карарына (2017 елның 6 июлендәге 15 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:9

1 абзацта «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393 номерлы «Недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләтүгә өметсез дип табылган недоимканы һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны юкка чыгару тәртибен раслау турында» Боерыгының 6 пункты белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 18 номерлы «Җирле салымнар, пеналар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 10 июлендәге 11 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» (2017 елның 6 июлендәге 15 номерлы редакциядә) карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 3 нче йорт буенча (балалар бакчасы бинасы), М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе
Л.М.Шиһапова